Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Лицей №2»
города Буинска Буинского муниципального района Республики Татарстан

РАССМОТРЕНО
педагогическим советом
протокол №1
от 28 августа 2025 г.

УТВЕРЖДЕНО
Директор МБОУ «Лицей №2»
г.Буинска БМР РТ
____________ Абрамова Л.В.
Приказ №104 о/д от 28 августа 2025 г.

Рабочая программа
дополнительного образования
«Нур»
художественной направленности
Возраст обучающихся 13-16 лет
Срок реализации 1 год
Составители: Садыкова Д.А.
Кабирова Г.Г.

г. Буинск, 2025 год

**2025/2026 нчы уку елында «Нур» драма түгәрәгенә йөрүче балалар исемлеге**

1. Кутбеева Алинә 9-а
2. Сибгатуллина Инзилә 9-а
3. Фатыйхова Мәликә 9-а
4. Юлдашова Азалия 9-а
5. Замалетдинова Назилә 9-б
6. Усманов Адель 9-б
7. Замалетдинов Марат 9-б
8. Аскарова Диляра 9-б
9. Хайретдинова Рания 9-б
10. Латыйпов Рөстәм 10-а
11. Галимов Илсаф 10-б
12. Каюмова Рузилә 10-б
13. Мифтахова Диләрә 10-а
14. Зайнутдинова Камилә 8-в
15. Шакирзянов Риналь 8-в
16. Газизуллина Илзира 8-а

Түгәрәк җитәкчеләре: Садыйкова Диләрә Әнәс кызы,

Кәбирова Гөлгенә Гарифҗан кызы

## Аңлатма язуы

Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырылды. “Драма” түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучыларны туплады. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Чөнки мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп. Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы булыр дигән фикергә килдем.

Һәр халык үзенә хас булган, гореф-гадәтләргә бай. Соңгы вакытта туган телебезгә, шулай ук борынгыдан килгән йолаларга игътибар бик нык артты, чөнки татар халкының, башка халыклар кебек үк тарихы, үткәне бик бай, йола-бәйрәмнәре һәм уеннары да күп төрле.

Түгәрәк программасын төзегәндә, укучыларны шушы халык бәйрәмнәре һәм йолалары үрнәгендә тәрбияләү, җыр-биюләрне, такмак-такмазаларны өйрәтү, шулар аша дуслык хисләре тәрбияләү, милли хисләр, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләү алгы планга куелды.

Түгәрәктә йөрүче укучыларны балалар шагыйрьләре, әсәрләре белән тирәнрәк тыныштыру, аларның әсәрләрен күбрәк уку теләге уяту максатлары да күздә тотылды.

Укучылар шулай ук үткән темалар ярдәмендә иҗади эш итеп шигырь, әдәби әсәр, мәсәл укырга өйрәнеп, сәхнәдә күрә белү, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерә ала.

Түгәрәккә йөрүче укучылар югарыда күрсәтелгән белем һәм күнекмәләрне камилләштерергә тиеш.

Түгәрәк дәресләрендә татар теле, әдәбияты, рәсем, җыр сәнгате, уеннар һәм сәхнә әсәрләре бәйләнештә бирелә. Дәресләр халкыбызның гореф-гадәтләрен, әдәбиятын, мәдәниятын өйрәнүгә нигезләнә.

Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы кулланыла.

**Программаның максаты.**
Театр түгәрәгендәге шөгыльләр аша укучыларның сөйләм телләрен, иҗади активлыгын үстерү өчен шартлар булдыру.

- Милли рухи байлыкны тирәнрәк күзалларга ярдәм итү;
- Татар халкының рухи әхлакый сыйфатларын ныклап үзләштерү;
- Туган якның тарихы һәм мәдәнияте белән танышу, традицияләрне һәм милли бәйрәмнәрне өйрәнү;
- Укучыларда милли үзаң тәрбияләү – халкыбыз тарихын яхшы белүче, милләте белән горурланучы шәхесләр тәрбияләү.

-“Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру”.

- җанлы сөйләмнең әдәби төре буларак сәхнә теленең үзенчәлекләрен аныклау һәм билгеләү.

- укучыда образлы сүзгә мәхәббәт уяту;

- сөйләгән чакта җаваплылык хисе тоярга, авазларны аңлаешлы итеп әйтергә өйрәтү;

- әдәби сөйләм кагыйдәләрен төшендерү, сүзне ничек әйтергә икәнен аңлату, әдәби әсәрне матур итеп укырга, дөрес аңларга, нык үзләштерергә әзерләү;

- укучыларда сәламәт тормыш алып баруның ихтыяҗларын булдыру

- Сәламәт тәндә - сәламәт акыл' шигарен пропагандалау.

**Түгәрәкнең бурычлары:**

1. Чыгыш ясау, аралашуга өйрәтү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү .
2. Укучыга үзенең сөйләм осталыгын, талантын сынап карарга шартлар тудыру, киләчәктә һөнәр сайларга юнәлеш бирү;
3. Әңгәмәдә катнашып, үз фикереңне әйтә белергә өйрәтү.
4. Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
5. Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
6. Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.
7. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.
8. Балаларның “ Татар сәхнә сөйләме” турындагы белемнәрен тирәнәйтү;
9. Радио, телевидение, халык алдында чыгышлар теле белән сәхнә теленең охшаш һәм аерымлыкларын ачыклау;
10. Халкыбызның милли традицияләре турындагы күзаллауны ныгыту;
11. Телебезнең матурлыгын күреп, яратырга өйрәтү.

**Шәхес үстерү нәтиҗәләре:**

- аралашу культурасын һәм кеше арасыда үзеңне дөрес тота белү кагыйдәләрен фориалаштыру;
- сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

- театр эшчәнлегенә омтылыш,үз-үзеңне камилләштерергә теләкне үстерү;
- мөстәкыйльлек, җаваплылык, активлык, пөхтәлек сыйфатларын үстерү;
- танып белүне, мөстәкыйль фикерләү сәләтен активлаштыру.
-

**Белем бирү нәтиҗәләре (предмет):**

- танып белү процессларын үстерү: игътибар, күзаллау, хәтер, образлы һәм логик фикерләүне камилләштерү;
- татар телендә җөмләдә сүз тәртибен һәм басымны дөрес кую, авазларны дөрес әйтү күнекмәрен үстерү;
- сөйләмнең тавыш сыйфатларын үстерү: дөрес сулау, артикуляция, тавыш көче; гәүдәне иркен тотарга өйрәтү; фантазияне, пластиканы формалаштыру;
- театр һәм театр сәнгате тарихы белән таныштыру;
- актер осталыгының теоретик нигезләрен бирү;
- спектакль өстендә эш этаплары белән таныштыру;
- сәхнәдә хәрәкәт кагыйдәләре белән таныштыру;
- грим салырга өйрәтү;
- иҗади һәм оештыру сәләтләрен үстерү.

Театр түгәрәге шөгыльләрендә сөйләм осталыгын үстерү максатында түбәндәге күнегүләрне үткәрү карала.

1. Сүз басымын кую.
2. Сулыш күнегүләре.
3. Тартык һәм сузык авазларны дөрес әйтү күнегүләре.
4. Тавыш һәм дикция күнегүләре.
5. Текстның эчке мәгънәсен ачыклау.
6. Мәгънәви басым кагыйдәләре.
7. Сөйләм тизлеге.
8. Сөйләм ритмы һәм аһәңе.

Театр түгәрәге шөгыльләрендә сәнгатьле сөйләм осталыгына өйрәтү сәнгать осталары үрнәгендә, әдәби әсәрләр нигезендә һәм практик күнегүләр белән ныгытылып алып барыла.

Театр түгәрәге программасы 68 сәгатькә (атнага 2 сәгать исәбеннән) 1 елга төзелде.

**Коллектив турында кыскача белешмә.**

- группаның составы: даими составка яңа укучылар өстәлде
- балаларны туплауның үзенчәлекләре: ирекле
- шөгыльнең төре: төркем белән
- укыту вакыты: 1ел
- укучыларның саны: 16
- укучыларның яше: 13,

-

- -16 яшь
- атналык сәгатьләр саны: 2 сәгать
- ел буена - 68 сәгать
- түгәрәкне үткәрү урыны: татар теле бүлмәсе (10)

**Өстәмә белем бирү дәресе программасының юнәлеше:**

Балаларның эстетик зәвыгын, иҗади фантазияләрен үстерү.
Балаларны традицияләребезгә нигезләнгән үзара аралашу культурасына өйрәтү.
Балаларның милли телен баету.
Сәләтле балаларны ачыклау

**Балаларның яшь үзенчәлекләре**

Балалар уку-танып белү эшләнгеченең башлангыч ысулларына ия, аларны камилләштерергә һәм баетырга омтылалар. Һәрберсендә сәнгатьле уку, сәхнәдә матур итеп чыгыш ясау теләге бар. Коллектив белән уртак тел табып, анда күмәк яши беләләр. Балалар үзләре алдына куелган бурычны яхшы аңлыйлар.

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре**

Балалар уку елы ахырына матур итеп шигырь, әкият сөйләргә, аларны сәхнәләштерергә өйрәнергә, үз-үзләрен сәхнәдә матур, иркен итеп тота белергә тиешләр.

Укытучылар көненә, Әниләр көненә, 8нче мартка спектакльдән өзек сәхнәләштерү.

“Туган тел” атналыкларында , “Нәүрүз” бәйрәмнәрендә чыгышлар ясау.

Г.Тукай туган көнендә катнашу, әкиятләрен сәхнәләштерү, шигырьләрен ятлау.

“Ният” конкурсында катнашу.

Фән яңалыклары белән танышып бару.

Танылган кешеләр белән аралашу, очрашуларга бару.

Театр, концерт, кичәләргә йөрү



**Курсның эчтәлеге**

| Бүлекләр исемлеге | Сәгать саны | Кыскача эчтәлек |
|---|---|---|
| **I. Кереш** | **1** | Кереш дәрес. Укучыларны туплау, түгәрәкнең эш планы таныштыру. Инструктаж үткәрү.<br>Түгәрәк әгъзаларының бурычлары. |
| **II. Татар халык авыз иҗатын барлыйбыз.** | **3** | Татар халкының милли йолалары, бизәнү әйберләре, музыка уен кораллары белән танышу. Календарь йолалар турында презентацияләп сөйләү. Халык авыз иҗаты әсәрләрен укучыларга таныту. |
| **III. “Театраль Идел буе” фестивалендә катнашу.**<br>1.Г.Тукайның “Шаян песи” шигыренә нигезләнеп эшләнгән театраль тамаша. | **10** | Г.Тукайның 140еллыгына багышланган чараларны башлап җибәрү. Тукай иҗатына мәхәббәт тәрбияләү. Эш сөючәнлек, йорт хайваннарына карата миһербанлык хисләре булдыру, гаиләдә дус яшәү нормаларын бирү. |
| **IV. “Сәяр” конкурсында катнашуга әзерлек.**<br>Рабит Батулла «Кичер мине, әнкәй”драмасы | **17** | Әсәрдә зур конфликт бар: заман һәм аналар арасында. Кемдер бала табасы килеп тә таба алмый, ә кемдер бала табу бәхетенә ирешеп тә, эгоистлыгы аркасында һәм заман кууы нигезендә, аннан баш тарта.<br>Әби – баба һәм эти - әни исә әлеге традицияләрне бүгенге көннәргә алып килгән буыннар. Нәкъ менә шушы буыннар арасында драматургик каршылык, характерлар бәрелешен ачыклау һәм сәхнәдә күрсәтергә омтылу. |
| **IV. Татар теле дөньясында.**<br>Фән олимпиадаларында, гамәли конференцияләрдә катнашу**.** | **12** | Укучыларның фонетик, орфоэпик, орфографик, лексик, грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү; иҗадилыкны, эзләнү – тикшерену мөмкинлекләрен үстерү, яшь талантларны барлау |
| **V.  Без – яшь артистлар “Сәнгать. Омтылыш. Талант.” исеме астында үткән фестиваль-конкурсында катнашу.**<br>Әхмәт Фәйзинең | **17** | Конфликтның тууын һәм үсүен, ярдәмче каршылыкларның асылын өйрәнеп, геройларның эш-гамәлләрен, тормыш позицияләрен, характерын аңларга ярдәм итү. Мәгълүматлы, зәвыклы, фикерле белә |

| | | |
|---|---|---|
| “Тукай”романы буенча эшләнгән “Кечкенә Апуш” әсәре. | | торган тамашачы тәрбияләү. Үз - үзеңне тоту культурасын формалаштыру.<br><br>Бәйрәмгә әзерлек эшләре алып бару, киемнәр әзерләү. |
| **VI. Шигъри сәхнә.** Шигырь конкурсларында чыгыш ясау. | **5** | “Татар сүзе”конкурсында, “Әдәби марафон”да, Тукай бәйрәмнәрендә чыгышлар ясау |
| **VII.Сәхнә уеннары. Татар халкының “Аулак өй” җырлы-биюле уенын сәхнәгә кую.** | **5** | Татар халкының сәхнә уеннары, такмак, такмаза, тел шомарткычлар турында мәгълүмат бирү. Сәхнә өчен куелган уеннарны өйрәнү, сәхнәдә кую. Татар халкының милли гореф-гадәтләренә ихтирам тәрбияләү<br><br>Балаларны парлы, күмәк биюләргә өйрәтү (бию элементларын кабатлау, көйгә басу, киемнәр әзерләү). Бәйрәмнәрдә чыгыш ясау. |
| **VIII. “Театр турында сөйләшәбез” .** “Син театр турында нәрсәләр беләсең?”, “Театр төрләре нинди була?” темасына викторина уздыру | **2** | Буа театры артистлары белән очрашу, балалар өчен куелган әсәрләрен карау |
| **IX. Йомгаклау.** | **1** | Эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясау. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.<br><br>Халкыбызның милли традицияләре турындагы күзаллауны ныгыту.<br>Телебезнең матурлыгын күреп, яратырга өйрәтү турында әңгәмәләр. |

**Искәрмә**:

Һәр түгәрәктә укучыларның иҗат эшләре тикшерелә, матбугатка күзәтү ясала, әдәбият-сәнгать яңалыклары җиткерелә һәм интернет язучылар сайтына күзәтүләр ясала, матбугатта килгән, район игълан иткән викториналарда, конкурсларда катнашу, презентация ясау, олимпиадага әзерләнү эшләре алып барыла.

**Календарь-тематик планлаштыру**

| № | Бүлек исемнәре һәм темалар | Оештыру формалары | Эшчәнлек төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **План буенча** | **Фак-тик** |
| 1 | **Кереш .**<br>1.Укучыларны туплау. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру.<br>2.Инструктаж үткәрү. Түгәрәк әгъзаларының бурычлары.<br>3. Татар театр сәнгатенең роле | Әңгәмә. | Танып белү. | 5.09<br>8.09 | |
| 2 | Татар халык авыз иҗатын барлыйбыз. Татар халкының милли йолалары | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 3 | Татар халкының музыка уен коралларлары, бизәнү әйберләре. | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 4 | Календарь йолалар. | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 5 | Г.Тукайның “Шаян песи”шигыре буенча театральләштерелгән тамашаны куюга әзерлек | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 6 | Спектакльдән өзекне видеодан карау | | | | |
| 7-8 | Рольләргә бүлеп уку | | | | |
| 9-13 | “Театраль Идел буе” конкурсында чыгыш ясауга әзерлек. Сәхнә әсәрен кабатлау. | Сәнгатьле сөйләм | уен | | |
| 14-15 | Сөйләм тизлеге.<br>Сөйләм тизлегенә йогынты ясаучы күренешләрне анализлау. | Сәнгатьле сөйләм | Танып белү | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Такмаклар, санамышлар әйтү. | | | | |
| 16 | Киенү-бизәнү осталыгы | Яңа белемнәр | Танып белү | | |
| 17 | Сәхнәдә чыгыш ясау | Әдәби иҗат | Социаль иҗат | | |
| 18-29 | Фән олимпиадаларына әзерлек | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 30 | Рабит Батулла иҗаты, татар театры тарихы белән танышу. | Танып белү Сэнгатьле уку | Әдәби иҗат | | |
| 31 | “Кичер мине,әнкәй” спктаклен видеодан карау. | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 32 | Драманы рольләргә бүлеп уку. Рольләрне ачыклау | Рольләргә бүлеп уку | Әдәби иҗат | | |
| 33 | Артикуляция гимнастикасы. Тел гимнастикасы. Жестлар. Җор теллелек. | Яңа белемнәр үзләштерү | Әдәби иҗат | | |
| 34 | Сәхнәдә үз-үзеңне тота белү. Алып баручы. Сөйләмдә көлү-көлдерү максатында ирония, юмор – мәзәк чаралары | Эшлекле уен | Әдәби иҗат | | |
| 35-37 | “Кичер мине,әнкәй” әсәре буенча эшне дәвам итү. Хәрәкәтләр. Киемнәр әзерләү. | Рольләргә бүлеп уйнау | уен | | |
| 39-40 | Аерым образлар өстендә эш. Мимика бирү юллары. | Рольләргә бүлеп уйнау | уен | | |
| 41 | Образлы сөйләү. Сөйләм үзенчәлекләре.Хисләрне җиткерү алымнары | Рольләргә бүлеп уйнау | уен | | |
| 42 | “Кечкенә Апуш” әсәрен куюга әзерлекне башлау. | Эшлекле уен | Әдәби иҗат | | |
| 43 | Рольләрне кабатлау. | Эшлекле уен | уен | | |
| 44 | Музыкаль бизәлешне кертеп уйнау.Интонация. Басым.Киенү-бизәнү осталыгы. Декорациянең роле. | Эшлекле уен | Күмәк иҗат | | |
| 45-46 | Өзекне сәхнәләштерүгә әзерлек. Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. | Әдәби иҗат буенча өстәмә дәрес | Әдәби иҗат | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 47 | Сәхнәдә чыгыш ясау | Әдәби иҗат | | | |
| 48 | Район китапханәсенә керү. Шагыйрь һәм аларның иҗатлары турында әңгәмә | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |
| 49 | Халыкара телләр көнендә катнашу өчен репертуар сайлау. | Әдәби иҗат буенча өстәмә дәрес | Танып белү | | |
| 50 | Сөйләм үзенчәлекләре | Сәнгатьле сөйләм | Танып белү | | |
| 51 | Интонация.Басым | Сәнгатьле сөйләм | Танып белү | | |
| 52-54 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Чыгыш ясау | Сәнгатьле сөйләм | Социаль иҗат | | |
| 55 | Тукай бәйрәмендә катнашу өчен репертуар сайлау. | Әдәби иҗат буенча өстәмә дәрес | Танып белү | | |
| 56-57 | Сөйләм үзенчәлекләре | Сәнгатьле сөйләм | Танып белү | | |
| 58-59 | Интонация.Басым | Сәнгатьле сөйләм | Танып белү | | |
| 60 | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре | әңгәмә | Танып белү | | |
| 61 | Чыгыш ясау | Сәнгатьле сөйләм | Социаль иҗат | | |
| 62 | Сәхнә уеннары. “Аулак өй” сәхнәләштерелгән уенының сценарие белән танышу. | Эшлекле уен | Күмәк иҗат | | |
| 63 | Сәхнә уеннары. . “Аулак өй” уенында катнашучыларның рольләрен билгеләү | Эшлекле уен | Күмәк иҗат | | |
| 64 | Сәхнә уеннары. “Куш кулым” җырлы-биюле түгәрәк уенын өйрәнү. сәхнәгә кую | Эшлекле уен | Күмәк иҗат | | |
| 65 | Сәхнә уеннары. “Зәңгәр чәчәк”, “Кәрия-Зәкәрия”, “Шома бас”, “Куш кулым” җырлы-биюле түгәрәк уеннарын сәхнәгә кую. Башлангыч сыйныф укучылары белән тәнәфесләрдә уйнау | Чыгыш ясау | Социаль иҗат | | |
| | **Театр турында сөйләшәбез** | | | | |
| 66 | Татар дөньясында беренче театр оешу, | Яңа белемнәр үзләштерү | Танып белү | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | беренче “карлыгачлары” турында фикер алышу. Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина | | | | |
| 67 | Буа театрына экскурсия | аралашу | Танып белү | | |
| 68 | Йомгаклау. | | | | |